*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**

(2024-2025 нче уку елы)
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 35**

**1. Халык әкиятләре турында исеңә төшер. Татар халык әкиятләренең төр үзенчәлекләрен барлап яз. Мисаллар китер. (6 балл)**

**Җавап:** Әкият – зур күләмле, гади яисә катлаулы, үзенчәлекле уйдырмага нигезләнгән ярымфантастик тылсымлы, маҗаралы эпик әсәр.

Хайваннар турындагы әкиятләр татар халык әкиятләренең бер өлешен алып торалар. Алар бик күп түгел. Мондый әкиятләрнең төп геройлары төрле кыргый һәм йорт хайваннары, җәнлекләр, кошлар, бөҗәкләр була, алар белән бәйле вакыйгалар аша кешеләр тормышы, алар арасындагы мөнәсәбәтләргә бәя бирелә.

Тормыш-көнкүреш әкиятләрдә көндәлек тормышта кешеләр белән була торган хәлләр турында сөйләнелә. Шул ук вакытта уйдырмага, могҗизага да урын бирелә. Мондый әкиятләрдә яхшылык һәм яманлык көрәше күрсәтелә. Тормыш-көнкүреш әкиятләрендә ялкаулык, саранлык, куркаклык, наданлык кебек сыйфатларның начарлыгы, зарарлы булуы сөйләнә, тырышлык, уңганлык, киң күңеллелек сыйфатлары мактала.

Тылсымлы әкиятләр – фантастик персонажлар, тормышта булмаган мифик геройлар, тылсымлы ияләр катнашуында төрле могҗизалы хәлләр һәм маҗаралар турында сөйләгән әкиятләр.

**2. Рәсемгә игътибар ит. Ул кайсы әсәргә карата ясалган? Әсәрнең исемен, авторын атап, аның кемнәр турында булуын яз. (5 балл)**



**Җавап:** М. Мәһдиев «Фронтовиклар». Әсәр фронтовик-укытучылар турында.

Әсәр геройлары – Рушад, Нәркис, Закиров, Хушият карт һ.б.

**3. «Мокамай» поэмасының авторын билгелә. (1 балл)**

а) Гаяз Исхакый

ә) Гомәр Бәширов

б) Галимҗан Ибраһимов

в) Һади Такташ

**Җавап:** в) Һади Такташ

**4. Шигырьнең исемен, авторын яз. Шигырьне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән төп хис-тойгыны билгелә. (7 балл)**

Һәр көн юлдан дистәләгән
Юлчы уза, тузан туза.
Һәм һәр юлчы – моңлы җырчы –
Имән җырын тыңлап уза.

Җилле көнне юлчыларны
Имән саклый җил-яңгырдан.
Җылы биреп җил-су үтмәс
Яшел чуклы юрганыннан.

Күләгәсе ял иттерә
Кырда эшләп арганнарны,
Кавыштыра айлы кичтә
Яшерен утта янганнарны.

**<u>Җавап:</u>** Муса Җәлил. «Имән».
Хис-кичереш – соклану, рәхмәт хисе.

**5. Портретка игътибар ит. Биредә кем сурәтләнгән? Бу әдип турында өч фактны искә төшереп яз. (6 балл)**



1) ________________________

2) ___________________________

3) ___________________________

**Җавап:** 1) М. Гафури 1880 елның 20 июлендә Башкортстанның хәзерге Җилем- Каран авылында укытучы гаиләсендә туа.

2) Троицк мәдрәсәсендә укыганда беренче әсәрләрен бастыра.

3) М. Гафури шигырьләр, мәсәлләр иҗат итә, аның «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Кара йөзләр», «Кар ялчы» һ.б. әсәрләре бар.

**6. Яхшылык ит тә мәңгегә оныт, диләр. Ничек уйлыйсың, бу дөресме? Бу турыда фикерләреңне яз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытма. (10 балл)**